ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**«2020 елга, 2021 һәм 2022 еллар план чорына Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты турында» Татарстан Республикасы Законының 7 статьясына үзгәреш кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2020 елның 23 апрелендә
кабул ителде

**1 статья**

«2020 елга, 2021 һәм 2022 еллар план чорына Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты турында» 2019 елның 30 ноябрендәге 93-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 7 статьясындагы 2 өлешенә (Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2020, № 1 (I өлеш), № 26 (I өлеш), аңа түбәндәге эчтәлекле 5 пунктны өстәп, үзгәреш кертергә:

«5) гадәттән тыш хәл шартларында һәм (яисә) әйләнә-тирәдәгеләр өчен куркыныч тудыра торган авырулар таралу янаганда территориаль мәҗбүри медицина иминияте программасы белән билгеләнгән медицина ярдәме күләмнәре киметелүгә бәйле рәвештә медицина оешмаларына алып бетерелмәгән керемнәрен компенсацияләү чараларын финанс белән тәэмин итү.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Президенты — Р.Н. Миңнеханов

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ • АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2020 ел, 29 апрель
№ 18-ТРЗ